Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил
№ 37-0

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы
№ под-2097/16

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы
№ 2

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы
№ 01-02/269

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы
№ 32и

# БОЕРЫК

13.10.2016

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсы турында» боерыкка үзгәрешләр кертү турында

«Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсын уздыру тәртибен төгәлләштерү максатларында, боерабыз:

1. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең 2015 елның 2 сентябрендәге 19 номерлы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының под-9233/15 номерлы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының 533 номерлы, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 01-02/629 номерлы, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының 30-П номерлы уртак боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

Әлеге боерык белән расланган «Ребенок в мире прав» – «Бала хокук даирәсендә» мәгълүмати-социаль видеороликлар республика конкурсы турында» нигезләмәдә:

3 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 3.5 пункт белән тулыландырырга:

«3.5. Конкурсның жюри составы Оештыру комитеты тарафыннан ел саен агымдагы елның 1 ноябренә кадәр формалаштырыла һәм раслана.»;

5.5 пунктның җиденче абзацында «17 ноябрьне кертеп» сүзләрен «15 ноябрьне кертеп» сүзләренә алмаштырырга;

5.12 пунктта «17 ноябрьдән дә соңга калмыйча» сүзләрен «15 ноябрьдән дә соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

6.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.4. Бүләкләү Конкурска нәтиҗәләр ясау тантанасында, агымдагы елның 20 ноябрендә - Бөтендөнья бала хокуклары көнендә узачак.

20 ноябрь ял көненә туры килгән очракта Конкурска йомгаклар ясау тантанасы Оештыру комитеты карары белән агымдагы елның 20 ноябре – ял көне алдындагы эш көненә яки агымдагы елның 20 ноябре – ял көненнән соңгы эш көненә күчерелә.

Конкурска йомгаклар ясау тантанасында катнашуга чакырыла торган затларның составы Конкурсны оештыру комитеты тарафыннан билгеләнә. Конкурска йомгаклар ясау тантанасы булачак урын һәм вакыт турындагы мәгълүмат агымдагы елның 16 ноябреннән дә соңга калмыйча Конкурсны гамәлгә куючыларның рәсми сайтларында урнаштырыла.».

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратына йөкләргә.

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил | Г.Л.Удачина |
| Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министры | Э.Н.Фәттахов |
| Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министры | В.А.Леонов |
| Татарстан Республикасы Юстиция министры | Л.Ю.Глухова |
| «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе | А.Р.Зарипов |